КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 19 апрель г.Казань № 264

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү дәүләт системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатлар хезмәте өчен түләү һәм адвокатларның түләүсез юридик ярдәм күрсәтү чыгымнарын компенсацияләү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 21 октябрь, 774 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 20 февраль, 103 нче; 2015 ел, 11 март, 144 нче; 2016 ел, 24 март, 164 нче; 2016 ел, 15 август, 563 нче; 2017 ел, 21 февраль, 111 нче; 2017 ел, 7 декабрь, 951 нче; 2019 ел, 20 сентябрь, 858 нче; 2023 ел, 11 март, 239 нчы, 2023 ел, 05 октябрь, 1237 нче, 2024 ел, 10 февраль, 75 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Түләүсез юридик ярдәм күрсәтүнең дәүләт системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатлар хезмәте өчен түләү һәм адвокатларның түләүсез юридик ярдәм күрсәтү чыгымнарын компенсацияләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 – 9 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Адвокат хезмәтенә түләү һәм чыгымнарын компенсацияләү түбәндәге документлар нигезендә башкарыла:

әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасы нигезендә форма буенча төзелгән адвокат тарафыннан бушлай күрсәтелгән юридик ярдәм реестрлары (алга таба - реестр);

бушлай юридик ярдәм күрсәтү турында килешүләрнең күчермәләре;

адвокатның әлеге Тәртипнең 4 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән чыгымнарын раслый торган юл документлары;

адвокатның әлеге Тәртипнең 4 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән чыгымнарын раслый торган документлар;

дәүләт һәм муниципаль органнарда, оешмаларда, судларда адвокат тарафыннан гражданның мәнфәгатьләрен күрсәтү турында әлеге Тәртипкә 3 нче кушымта нигезендә белешмәләр;

гражданнар тарафыннан бушлай юридик ярдәм алу өчен тапшырылган әлеге Тәртипнең 4 нче кушымтасында күрсәтелгән документларның күчермәләре;

әлеге Тәртипкә 5 нче кушымта нигезендә форма буенча бушлай юридик ярдәм күрсәтү турындагы актларның күчермәләре.

6. Хезмәт өчен түләүне һәм чыгымнарны компенсацияләүне гамәлгә ашыру өчен адвокат ай саен, бушлай юридик ярдәм күрсәтелгән айдан соң килүче айның 10 числосыннан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән документларны тапшыра.

7. Әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән документлар адвокат тарафыннан тапшырылган көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 20 көн эчендә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы аларның тулылыгын, рәсмиләштерүенең дөреслеген һәм чынлыгын тикшерә һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына реестр күчермәсе белән чыгымнар өчен акча бүлеп бирүгә заявка җибәрә яисә адвокатка документларны эшләп бетерү кирәклеге турында хәбәр итә.

8. Эшләп бетерелгән документлар аларны эшләп бетерү кирәклеге турында адвокатка мәгълүмат биргән көннән соң календарь көннәрдә исәпләнә торган 10 көн эчендә кабат Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына тапшыра.

Документларны кабат тикшерү адвокат тарафыннан эшләнеп беткән документлар тапшырылган көннән алып эш көннәрендә исәпләнгән 10 көн эчендә башкарыла.

9. Адвокат хезмәте өчен түләүдән баш тарту һәм аның чыгымнарын компенсацияләү өчен түбәндәгеләр нигез була:

Татарстан Республикасы Законы нигезендә бушлай юридик ярдәм алу хокукына ия гражданнар категориясенә карамаган гражданга бушлай юридик ярдәм күрсәтү;

әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән документларны һәм белешмәләрне тапшырмау яисә тулы күләмдә тапшырмау;

әлеге Тәртипнең 8 пунктында күрсәтелгән җитешсезлекләрне бетергәннән соң документларны тапшырмау;

тапшырылган документларның дөрес булмавы.»;

әлеге Тәртипкә 2 нче һәм 3 нче кушымталарны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлгән).

әлеге Тәртипкә 4 нче кушымтаның 1 пунктындагы «в2» пунктчасында «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәү» сүзләреннән соң «яисә Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләре» сүзләрен өстәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Цифрлы Татарстан» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2023 ел, 16 май, 597 нче, 2023 ел, 3 октябрь, 1215 нче, 2023 ел, 22 декабрь, 1667 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Цифрлы Татарстан» Татарстан Республикасы дәүләт программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне цифрлаштыру» төбәк проекты паспортында:

2 бүлекнең 2 пунктындагы 2.31 пунктчасында:

2 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Хисап чорында Татарстан Республикасында бушлай юридик ярдәм күрсәтүнең гомуми саныннан электрон сервислардан файдаланып, Татарстан Республикасы дәүләт системасында катнашучылар күрсәткән бушлай юридик ярдәм өлеше»;

13 нче графада «Бушлай юридик ярдәм» сүзләрен «Хокукый ярдәм» сүзләренә алмаштырырга;

3 бүлекнең 2 пунктындагы 2.31 пунктчасының 2 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Хисап чорында Татарстан Республикасында бушлай юридик ярдәм күрсәтүнең гомуми саныннан электрон сервислардан файдаланып, Татарстан Республикасы дәүләт системасында катнашучылар күрсәткән бушлай юридик ярдәм өлеше».

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында юстицияне үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2022 ел, 1 июль, 618 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 3 октябрь, 1217 нче, 2023 ел, 29 декабрь, 1750 нче, 2024 ел, 23 март, 177 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган «Татарстан Республикасында юстицияне үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

I бүлекнең  егерме өченче - егерме дүртенче абзацларын үз көчләрен югалткан дип танырга;

«Татарстан Республикасында юстицияне үстерү» процесслы чаралар комплексы паспортында:

1 бүлекнең 8 пунктындагы 8.1 пунктчасының 13 нче графасында «Бушлай юридик ярдәм» сүзләрен «Хокукый ярдәм» сүзләренә алмаштырырга;

6 бүлекнең 8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «8. | Юстиция өлкәсендә дәүләт сәясәтен Татарстан Республикасы вәкаләтләре чикләрендә гамәлгә ашыру | | | | |
| 8.1. | «Бушлай юридик ярдәм күрсәтелде» нәтиҗәсе | 01.01.2024 | 31.12.2024 | хисап | «Хокукый ярдәм» мәгълүмат системасы |
| 8.1.1. | «Граждан бушлай юридик ярдәм алуны сорап мөрәҗәгать итү» контроль ноктасы | 01.01.2024 | 31.12.2024 | гариза | «Хокукый ярдәм» мәгълүмат системасы |
| 8.1.2. | «Граждан бушлай юридик ярдәм алу» контроль ноктасы | 01.01.2024 | 31.12.2024 | хисап | «Хокукый ярдәм» мәгълүмат системасы |
| 8.1.3. | «Адвокат хезмәте өчен түләү» контроль ноктасы | 01.01.2024 | 31.12.2024 | хисап | Татарстан Республикасы |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Юстиция министрлыгы мәгълүматлары |
| 8.2. | «Татарстан Республикасы дәүләт юридик бюросы» дәүләт казна учреждениесе эшчәнлеге финанс белән тәэмин ителде» нәтиҗәсе | 01.01.2024 | 31.12.2024 | хисап | Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы мәгълүматлары». |
| | | | | | |

4. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бушлай юридик ярдәм» мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 ел, 22 октябрь, 953 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 - 2028 елларга Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча стратегияне раслау турында» 2021 ел, 24 декабрь, 1285 нче карары белән расланган 2022 - 2028 елларга Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча стратегиянең II бүлегенең 2.4 бүлекчәсенең унынчы һәм унберенче абзацлары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында юстицияне үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2022 ел, 1 июль, 618 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында юстицияне үстерү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 ел, 29 декабрь, 1750 нче карары.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү дәүләт системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатлар хезмәте өчен түләү һәм адвокатларның түләүсез юридик ярдәм күрсәтү чыгымнарын компенсацияләү тәртибенә 2 нче кушымта (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 19 апрель, 264 нче карары редакциясендә)

Форма

Адвокат тарафыннан түләүсез юридик ярдәм күрсәтү һәм аны күрсәтү белән бәйле тотылган чыгымнар реестры,
20____ елның ______________________

<table>
<tr><td rowspan="2">__________ номерлы өчен</td><td rowspan="2">Бушлай юридик ярдәм күрсәткән адвокат үз эшчәнлеген алып барган адвокат оешмасы исеме</td><td rowspan="2">Адвокат Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда)</td><td colspan="3">Бушлай юридик ярдәм алучының исеме</td><td rowspan="2">Түләүсез юридик ярдәм төре*</td><td rowspan="2">Бушлай юридик ярдәм күрсәтү очраклары*</td><td rowspan="2">Хезмәт өчен түләү күләме, сум</td><td colspan="3">Адвокатның чыгымнары турында белешмәләр</td><td rowspan="2">Искәрмә</td></tr>
<tr><td>Ф.И.А.и. (соңгысы – булганда)</td><td>адресы</td><td>бушлай юридик ярдәм алуга хокукы булган гражданнар категориясе, аңа бушлай юридик ярдәм алучы керә**</td><td>юл бәясе **, сум</td><td>сәфәрләр саны**</td><td>башка чыгымнар, сум **</td></tr>
<tr><td>1</td><td>2</td><td>3</td><td>4</td><td>5</td><td>6</td><td>7</td><td>8</td><td>9</td><td>10</td><td>11</td><td>12</td><td>13</td></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td colspan="2">Барлыгы, сум</td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
</table>

Адвокат _________________ ______________________
(имза) (имзаны таркатып язу)
20___ ел, «___» _________

М.У.**

*"Татарстан Республикасында бушлай юридик ярдәм күрсәтү турында” 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә.

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 21 октябрь, 774 нче карары белән расланган Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү дәүләт системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатлар хезмәте өчен түләү һәм адвокатларның түләүсез юридик ярдәм күрсәтү чыгымнарын компенсацияләү тәртибенең 5 пункты нигезендәраслый торган документлар булганда.

***Адвокат оешмасы мөһере.

______________________________________

Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү дәүләт системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатлар хезмәте өчен түләү һәм адвокатларның түләүсез юридик ярдәм күрсәтү чыгымнарын компенсацияләү тәртибенә 3 нче кушымта (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 19 апрель, 264 нче карары редакциясендә)

Форма

Адвокат тарафыннан дәүләт һәм муниципаль органнарда, оешмаларда, судларда граждан мәнфәгатьләрен тәкъдим итү турындагы белешмә

Адвокатка бирелгән_______________________________________

(Адвокат Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда) (тулысынча))

аның 20___ елның «____» ________ мәнфәгатьләрен яклавы:

_____________________________________________________________________________

(Граждан Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда) (тулысынча))

_____________________________________________________________________________

(дәүләт (муниципаль) органы, оешма исеме)

Дәүләт (муниципаль) органы, оешма, суд органы җитәкчесе

______________ _________________________

(имза) (имзаны таркатып язу)

20__ ел, «___» ___________

М.У. (булганда)

________________________________